БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» 04 2021 ел № 160

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчаларының) төп гомуми белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 29 августындагы 289 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитеты карарына үзгәреш кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Россия Федерациясенең Федераль законы, «Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2020 елның 31 июлендәге 373 номерлы Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 29 августындагы 289 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчаларының) төп гомуми белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.9 пунктның 17 абзацын төшереп калдырырга;

1.2. 1.9 пунктның 22 абзацын төшереп калдырырга;

1.3. 2.1. пунктында «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру

тәртибен раслау турында» 2013 елның 30 августындагы 1014 номерлы Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы» сүзтезмәсен төшереп калдырырга;

1.4. 2.3 пунктта «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 30 августындагы 1014 номерлы Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы» сүзтезмәсен төшереп калдырырга;

1.5. 2.5 пунктның 4 абзацында « - туу турында таныклык мәгълүматлары» сүзтезмәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: « - чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;»;

1.6. 2.5 пунктта «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 30 августындагы 1014 номерлы Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы» сүзтезмәсен төшереп калдырырга;

1.7. 2.9 пунктта «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 30 августындагы 1014 номерлы Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы» сүзтезмәсен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://baltasi.tatarstan.ru веб-адресы буенча Балтач муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе — А. Ф. Хәйретдинов